| | |
|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 март № 166

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында» 2017 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы карары белән расланган 2017 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында» 2017 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 7 февраль, 63 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2017 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«2017 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте» дигән 2 бүлекнең «2017 елда хосусыйлаштырылырга тиешле дәүләт унитар предприятиеләре исемлеге» бүлекчәсендә

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасының дәүләт заказы, инвестиция эшчәнлеге һәм төбәкара элемтәләр агентлыгы» дәүләт унитар предприятиесе | Казан шәһәре» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| |
|---|
| «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентаризация бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесе | Казан шәһәре». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\166.docx